# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
# КНӘЗ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

## КАРАР

«03» апрель 2024 ел Татарстан поселогы № 8

**«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кнәз авыл җирлеге составына керүче Чершелы авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 17 ноябрендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына һәм 2023 елның 17 ноябрендәге 2 номерлы Тукай муниципаль районы Кнәз авыл җирлеге Чершелы авылында гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кнәз авыл җирлеге Чершелы авылында гражданнар җыенын билгеләү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Тукай муниципаль районы «Кнәз авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы, «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының Кнәз авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында» нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кнәз авыл җирлеге Советының 2019 елның 05 декабрендәге 12/4 номерлы карары нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кнәз авыл җирлеге составына керүче Чершелы авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 17 ноябрендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына һәм 2023 елның 17 ноябрендәге 2 номерлы Тукай муниципаль районы Кнәз авыл җирлеге Чершелы авылында гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча 2024 елның 14 апрель 13.00 сәгатькә гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез үзгәрешләр кертергә ризамы:

1) түбәндәге редакциядә бәян итеп, гражданнар җыенына чыгарылган һәм кабул ителгән «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кнәз авыл җирлеге составына керүче Чершелы авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 17 ноябрендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына:

«- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка ярдәмче станцияләрне һәм алар урнашкан мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элементләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (Чыршылы торак пунктында яктырткычлар сатып алу, урам утларын монтажлау һәм урнаштыру);

«-торак пункт чикләрендә җирле билгеләнештәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Чыршылы т.п. юлын ремонтлау);

2) түбәндәге редакциядә бәян итеп, 2023 елның 17 ноябрендәге 2 номерлы Тукай муниципаль районы Кнәз авыл җирлеге Чершелы авылында гражданнар җыены карарына:

«- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка ярдәмче станцияләрне һәм алар урнашкан мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (Чыршылы торак пунктында яктырткычлар сатып алу, урам утларын монтажлау һәм урнаштыру);

«-торак пункт чикләрендә җирле билгеләнештәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Чыршылы т.п. юлын ремонтлау);

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы, Кнәз авыл җирлеге, Чершелы авылы, Луговая ур., 1 йорт.

4. Халык җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы Кнәз авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кнәз авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә махсус мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarsatan.ru) урнаштырырга.

6. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Тукай муниципаль районы
Кнәз авыл җирлеге Башлыгы Ф.Ф.Хафизова